**Г.Р.Гайнуллина**

**Казан,**

**Казан (Идел буе) федераль университеты**

**Т.Галиуллин әсәрләрендә автор тавышы(“Кияү”повесте үрнәгендә)**

Язучы Тәлгат Галиуллин хикәя-повестьларында әдәби концепция билгеләү өчен “бөтенлекле образ тудыру аша фикер әйтү” [2;158] юлын һәм автор тавышының, карашының өстенлекле урынына дәгъва иткән хикәяләү формасын сайлый.

Т.Галиуллинның 90 елларга караган әдәби иҗатында автор сүзенең урнаштырылуы, персонажлар композициясе, сюжет-вакыйгаларны сурәтләү өчен табылган модус бер объектка - кешенең холык-табигатенең асылын аңлатуга хезмәт итә. “Кияү” повестенда (1994) автор тарафыннан төп герой буларак тәкъдим ителгән Сәгыйрь образына шул яссылыкта бәя бирү күздә тотыла.

Повестьның исеменә геройның укучы кабул итәргә тиешле бер ягы – вакыйгаларда кияү буларак катнашуы чыгарыла. Тормыш-чынбарлыктагы урынын “көтүдән артта калган бүре ботарлаган сарык” дип билгеләгәннән соң автор аның гамьсез эчке дөньясын кора, шул ук вакытта берөзлексез автор тавышын ишеттерә, хикәяләүче позициясендә катнаша. Төп объектны үткәрү өчен Т.Галиуллин аукториаль нарратив, гетеродиегетик хикәяләү юлы сайлый. Әсәрдә сурәтләнгән дөньяда хикәяләүче вакыйгаларда катнашмаса да, үзәк бәяләү ноктасы автор карашы рәвешендә тәкъдим ителә. Хикәяләүче сүзе субъектив образны тормышның әчесен-төчесен күп татыган, тәҗрибә туплаган акыллы ир заты буларак билгеләп куя: “Әйе шул, капылт чыгып котырынган бураннан соң туган тыныч халәт озакка бармый. Артыннын йә дуамал

яңгыры килеп җитә, йә үтәдән-үтә җиле ком бураннарын уйната башлый.” Әсәр структурасында хикәяләүченең бу урыны ныгытыла.

Повесть өйләнү-тормыш итә башлау вакыйгаларын кабатлау кебек сюжет сызыгына корылган. Хикәяләүче алдан ук тасвирлау модусын билгели: “мәзәк кенә булды аның гаилә башлыгы дигән югары дәрәҗәне алуы.” Вакыйгалар Аксубай мишәренең Львов хохоллары янына килеп эләгүе белән башлана, ягъни чит/үз бинар оппозициясе оештырыла. Чит җиргә бәянең егет теле белән бирелүе персонажны әле тормышта үз юлын тапмаган “бала” позициясенә урнаштыра: “Һич кенә дә авыл тормышына охшамаган кырыс тәртибе, ефрейтор, сержантның җилкәсенә әллә ничә йолдыз чәнечкән эфисәрләрдән дә хәтәр кыланып, борынны иллэм чөеп йөрүләре, сүтелә-җыела торган автоматлары, тимер кашык, кружкалары – һәммәсе аның өчен үзгә бер яшәеш иде.” Бинар оппозициянең эчтәлеге – “үзгә яшәеш”нең үзгә кануннары алдында югалып калган әхлакый нигез, әдәп кануннарының гадәткә кергән гамәл булып ныгымагынлыгы.

Кузла (козел)-кәҗә әдәби детале повесть структурасында вакыйгаларны бер төенгә җыеп тора. “Коңгырт күн белән тышланган, җитмәсә җене сөймәгән хайван исеме белән аталган, җансыз, йонсыз, шәрә, чит як “козел”ы” Сәгыйрь чынбарлыгына килеп кергән ят әдәп, үзгә рух, аңлаешсыз гамәлләрнең белдерелеше, авторның табышы да. Хохол егетләренеке дип белдерелгән реплика (“Татарин ишәк дип белә аны. Шуңа атланып базарга йөрергә өйрәнгән инде ул. Нишләсен.”) башка милләтләрнең татарга мөнәсәбәтен белдерә. Бу авторның караш ноктасы буларак та тамгалана: “Урта Азия халкы, татар, башкорт, чуаш, ар, мукшы – алар өчен барысы да бер милләт”.Әдип татар милләтенә булган мөнәсәбәтнең тарихны ялган, сафсата белән тутыру нәтиҗәсе икәнен усал көлү алымы белән күп әсәрләрендә белдерә.

Татар егетенең кәҗәне буйсындыра алмау вакыйгасы башка вакыйгаларны оештыра, үз тирәсендә туплый, дидек. Сәгыйрьнең кәҗәдән

сикерүе - максатына ирешү ноктасы – ят кануннарга каршы торырлык көч туплау вакыты ул. Светлана – ят мохиттә пәйда булган сихри гүзәллекне белдерү вазифасын башкарган персонаж. Автор Сәгыйрьне солдаттан яшь егет позициясенә урнаштырып, рухи-әхлакый эзләнүләр, эчке потенциалны барлау юлына бастыра. Сатира угы "борынын канаткан чибәр солдатик"ка юнәлтелгән икәнлеген автор укучыга һәр деталь белән искәртә (кызның ап-ак кечтеки кулъяулыгы белән борынын изгәләве, майорның әллә әүлия-томчы, әллә оста оештыручы булуданмы, аңа "кияү" дип эндәшүенә гаҗәпләнүе). Автор егетнең чит пространствода үз-үзен тотышына трагизм сала. Әйтик, үзенең "данлыклы совет армиясе укчысы" булуы белән ихластан горурланган егет сөеклесенең "сөйгәннәре" - ике мужикның янавына гарьләнә: "Иншалла, бу юлы борыны да канамады. Әмма гарьләнде." Борын канау деталенә салынган эчке мәгънә аша автор егеттә каршы торырлык потенциалга басым ясый. Ләкин егеттә көрәшү, гаделлекне яклау теләгеннән буйсынып исән калу теләге көчлерәк. Егетләр белән очрашу вакыйгасы сюжетны төгәл эзгә сала, укучы финалны алдан "укый". Светлананың өйләнешергә тәкъдим ясавы вакыйгасында егет телендәге җаваплылыкның ("Өйләнү – уен эш түгел. Без әле бер-беребезне бик аз беләбез... Татарстанга кайтырга кирәк. Анда минем әни, балаларым") күңел түренә кереп урнаша алмаган ерак бер хакыйкать кебек томанлы хис икәнлеге бәяләнә. Автор сатирасы кертелү егетнең үзенә биргән бәясен тамгалау һәм ышанычсызлыкның нигезен билгеләү өчен кирәк: "Кызның эти-әнисен ташлап, мәми авыз авыл малаена ияреп, билгесезлеккә чыгып китәргә риза булуын чын сөюгә юраган Сәгыйрь томаулы борын кебек йомшый барды."

**Әхлакый бөтенлекнең нигезе кешенең үзенә куйган бәясе белән билгеләнә** дигән автор карашы балалар йортында үскән Биктимер аганың дөньяга карашы белән дә раслана: "Биктимер ага үзен бәхетле язмышлы кешегә санап яшәде. "Ап-ак беләкле, зур күзле, олы артлы хатыным бар,

ни кирәк миңа тагын", дип Сәгыйрь алдында мактанырга ярата иде. Һәркемнең бәхетне үз аңлавы, бәяләү дәрәҗәсе бар шул." Автор ике татар кешесен чит/үз оппозициясендә тасвирлый. Чит-ят мохиткә кияү итеп сайланган ике буын вәкиле кимсенеп яшәүче ятим бала позициясенә урнаштырылалар. Автор сатирасы үзләрен Күчем хан нәселеннән санап горурланган "кияүләр"нең ят булуы белән һәрвакыт ымсындырып тора торган  чит матурлыкка коллыкка төшүне бәхет санауларына юнәлтелә. Нәтиҗәдә алар тудырган мохитның башкаларга бәхетсезлек китерүе билгеләнә.

Т.Галиуллинның теле, язу стиле хакында тәнкыйть күп язды. Әдипнең күп әсәрләрендә сатирик-ироник модус көчәя барган саен вакыйга сайланышы да кыюрак, буяулар да кителмәгән төсмер алалар. Әлеге повестьта зөфаф киче вакыйгаларының тасвирланышы ялган матурлыкның ялганга корылган мөнәсәбәт таләп итүен сатирик-ироник модуска төреп бирү өлеше ул: "Югары әхлаклы, суфый татар әдәбияты яшьләрне бу тормышка әзерләми... Алдагы тормышында Сәгыйрь хатынының тәнен яратып яшәде." Әсмага өйләнү вакыйгасы  беренчесенә бәя бирү, чын матурлыкны тасвирлап бирү өчен урнаштырыла: "Ир-атның төнге кояшы – хатыны, дип юкка гына әйтмиләр икән. Сәгыйрь Әсмага тиз ияләште. Сипкелләреннән җылылык, яктылык, талгын ягымлылык иңеп торгандай тоелды аңа.Сәгыйрь вакытында кайнар ризыгын, өчпочмагын, коймагын, пәрәмәчен, чөгендерле катыгын ашап, тынычлыкка сеңде, рәхәткә тарды".

Шәхеснең рухи эзләнүләре юлын тасвирлау пространство бирелешенә мәгънә салу аша алып барыла. Ирнең алдануы – укучы өчен көтелгән вакыйга шәхеснең үз-үзеннән качарга омтылышы кебек оештырыла. Азгын кызының Львовтан китүен көткән ата һәм ияртеп җибәрелгән "байлыгы"ның туган ягы Аксубайда күзгә чалынуын теләмәгән ир хисләре кисешә – чит җиргә качып котылырга кирәк.

Нәтиҗәдә ялганга корылган чынбарлык  җимерелә. Ата вафат була, ир буйдак кала. Ирне “күгәрченнәр оясы янында – бишенче катта ялгыз калдырып”, автор кияүнең гадәткә кергән буйсыну гамәлен сатира объекты итә: “Светасы белән яшәгәндә төшләрендә күргән ирекнең, бәйсезлекнең аңа һич кирәге юк, буйсынып, баш бөгеп, тез чүгеп яшәү җиңелрәк икән ләбаса.”

Вакыйгалар барышында чын матурлыкка автор бәясен тәгаенләштергән Әсмага өйләнү килеп керүгә хикәяләүче сөйләме үзгәрә. Матурлыкның эчтәлеге күгәрчен оясы – йортка Әсма бәясе кебек оештырыла, бу исә үз чиратында автор карашы кебек укыла: “Хәерче, ямьсез бүлмәгә күз салды да, “Миңа байлык кирәкми. Дөньяда иң олы куаныч, иң затлы нәрсә – кеше күңеле. Күңелең чиста, ниятең хушлы булса – миңа шул баштан ашкан”, дип өстәүне кирәк тапты.”Авторның тормыш юлы сайлагандагы бәйрәмнәрне янәшә куюында  матурлыкның эчтәлеге кабатланганы тоемлана: “Беренче март көне иде...Биктимер агай фатирында дус-иш туйлап ята...” Икенчесе: “Дусларын, якыннарын чакырып алырга булдылар. Туй урынына...Сәгыйрь әнисе янында яшәгәндәге кояшлы аланлы балачагына кайткан шикелле хис итте үзен...” Ниһаять, кешенең гомер дәвамында эзләгән матурлыгының эчтәлеге табыла. Ул – гасырлар дәвамында формалашкан, бабаларыбыз каны, акылы аша сиңа тапшырылган син ачарга тиешле синең милли моңың  - балачагыңда күңел түренә кереп урнашкан игелек, ихласлык, мәрхәмәтлелек, сафлык. Шул хисләрнең синең гадәткә кергән гамәлең булып әверелүе – бәхетнең нигезе, ди автор. Пространство үзгәреше күңел халәтенең үзгәрешенә ишарә: “Яңа гаиләнең хәленә кереп, Сәгыйрьләрне, иске йорттан булса да, ике бүлмәле фатирга күчерделәр.”

Соңгы вакыйга очраклы гына максатына ирешкән ирнең башлаган юлына ни дәрәҗәдә җаваплы була алуын бәяләү өчен тәкъдим ителә. “Каралмаган зиратка охшап калган фатирында  карт кияү” сурәте  - яшәү

белән үлем, өмет-өметсезлек чигендә калган ялгыз шәхес тасвиры  ул: “Ә кайгы кешеләрне гел аерым-аерым эзләп йөри икән шул”. Кеше бары үзе генә үзенең матурлыгын тоя, аны ача ала, үз потенциалы, эчке дөньясы, гамәлләре өчен җаваплы була ала, ди Т.Галиуллин.

Кулланылган әдәбият исемлеге:


1. Галиуллин Т.Н.Мәкер:повестьлар һәм хикәяләр/Тәлгат Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. – 302 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Замана балаларын сурәтләү / Д.Заһидуллина // Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңалыклар). – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 158-168.